**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**"АЕРЫМ ПРЕДМЕТЛАР ТИРӘНТЕН ӨЙРӘНЕЛӘ ТОРГАН**
**2НЧЕ АЛЕКСЕЕВСК УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ"**
**МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**

| **"КАРАЛДЫ"** | **"КИЛЕШЕНДЕ"** | **"РАСЛАНДЫ"** |
|---|---|---|
| МБ җитәкчесе | «2 нче Алексеевск УГББМ" МБГБУ директор урынбасары | «2 нче Алексеевск УГББМ" МБГБУ директоры |
| ______Замалиева И.Х | ______Ягудина Л.Р. | ______Липлянина Л.Н. |
| МБ утырышы беркетмәсе №__1__ __25__ август 2016 ел | __24__ август 2016 ел | ______ номерлы боерыгы ______ август 2016 ел |

**Татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

**Замалиева Илсөяр Хәнифовнаның**

**1 "А" сыйныфы өчен татар теле һәм әдәби укудан**

**эш программасы**

Педагогик совет утырышында каралд[ы]

__1__ номерлы беркетм[әсе]

__31__ август 2016 е[л]

2016-2017 уку елы

## I.<u>Укыту предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре</u>

**Сыйныф** 1а сыйныфы (татар төркеме)

**Сәгать саны:** 132 сәгать, атнага 4 сәгать.

”Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына ана теле һәм әдәбият укыту программалары” 1-11 нче сыйныфлар. Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2011ел. нигезендә төзелгән планлаштыру

**Дәреслек :**

1) Ф.Ш.Гарифуллина, И.Х.Мияссарова .Әлифба: Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 1 нче сыйныфы өчен дәреслек( татар телендә сөйләшүче балалар өчен) . – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2012.

2) Ф.Ф.Харисов, Г.Д.Сираҗиева.Татар теле: Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 1 нче сыйныфы өчен дәреслек( татар телендә сөйләшүче балалар өчен) . – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2012

Эш программасы түбәндәге документларга нигезләнеп төзелде:

1. Программа: “Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына ана теле һәм әдәбият укыту программалары” (Ф.Ф.Харисов, Ч.М. Харисова,В.А. Гарипова, Р.Р. Җамалетдинов, Р.Ф.Җамалетдинова. Казан. “Мәгариф” нәшрияты, 2010)
2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең төп гомуми белем бирү баскычында гомуми башлангыч белем бирү программасы.
3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем мәктәбе”нең 2016-2017 уку елына укыту планы (№1 педсовет протоколы, 31 август 2016 ел).

**Укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:**

-ана теленең төп берәмлекләрен һәм аларның билгеләрен белү;

-телдән һәм язма сөйләм, диалог, монолог,аралашу ситуацияләрендә тел стильләре, текст төшенчәләрен аңлау һәм гамәлдә дөрес куллану;

-тыңлап аңлау һәм уку буенча телдән һәм язма рәвештә(радио,телеведениедә һ.б.) хәбәр ителгән мәгълүматны аңлау;

-сөйләү һәм язуда татар әдәби теленең төп нормаларын(орфоэпик,лексик,грамматик,орфографик һәм пунктуацион) саклау һәм сөйләм әхлагы нормаларын үтәү;

-татар теленең фонетик, лексик системаларын һәм грамматик төзелешен үзләштерү;

-сүзләрне төзелеше һәм язылышы буенча тикшерә белү;

-сорауларга тулы һәм дөрес итеп җавап бирү;

-төрле темаларга әңгәмә кору,үз фикереңне яклап,әңгәмә-бәхәс формасында сөйләшү күнекмәләренә ия булу;

-тәкъдим ителгән текстларны рус теленнән татар теленә һәм татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү;

-ана теленең башка фәннәрне өйрәнү һәм белем алу чарасы икәнен аңлау

### Укытуның предмет, метапредмет, шәхси нәтиҗәләре

***Шәхси нәтиҗәләр:***

1. Туган илгә карата шәхси караш булдыру
2. Чын кеше сыйфатлары булдыру
3. Мөстәкыйльлелек һөм җаваплылык үстерү
4. Этик хисләр, мөлаемлылык үстерү
5. Рухи-әхлакый идеалларына китерү
6. Олылар белән хезмәттәшлек
7. Аралашу культурасы күнекмәләре

***Метапредмет нәтиҗәләр:***

1. Аң - белем үстерү
2. Проблемаларны мөстәкыйль рәвештә таба алу
3. Эзләнү юлларын һөм нәтиҗәләрен ачыклау
4. Логик фикерләү:чагыштыру, синтез, анализ ясый белү
5. Конфликтлы ситуацияләрдән чыгу юлын табу
6. Укучыларның образлы, логик фикерләвен үстерү

***Предмет нәтиҗәләр:***

1. Россиядә күп милләт халыкларының төшенчәсен бирү
2. Татар теленең төп төшенчәләр буенча башлангыч белем ( фонетик, лексик, грамматик)
3. Татарча югары сөйләм культурасы формалаштыру
4. Туган телнең орфоэпик, лексик, грамматик төшенчәләре
5. Сүз турында башлангыч төшенчәләр формалаштыру
6. Уку, язу гамәлләре формалаштыру
7. Сүзгә фонетик анализ ясый белү

***Универсаль уку гамәлләре формалаштыру:***

***Танып белү универсаль уку гамәлләре:***

1. Дәреслектә ориентлаша белү
2. Шартлы билгеләрнең телен белү
3. Рәсем һәм схемалар нигезендә биремнәр үтәү
4. Төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру
5. Материаль объектлар кулланып биремнәр үтәү

6. Дәреслек һәм мөстәкыйль эш дәфтәрендәге мәгълүматлар белән эшли белү

***Регулятив универсаль уку гамәлләре:***

1. Кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу
2. Гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау
3. Үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү
4. Тормыш тәҗрибәсен куллану
5. Эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү

***Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре:***

1. Дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә таныпбелү инициативасы күрсәтү
2. Үз уңышларың/уңышсызлыкларың турында фикер йөртү
3. Үз мөмкинлекләреңне бәяләү
4. Үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру
5. Мәгънә барлыкка китерү («Минем өчен моның нинди мәгънәсе һәм әһәмияте бар?» - дигән сорау куйю)

***Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:***

1. Тормыш тәҗрибәсен куллану
2. Күршең белән хезмәттәшлек итү
3. Үз фикереңне һәм позицияңне формалаштыру
4. Уртак эшчәнлеккә һәм гомуми чишелешкә килү
5. Партнёрның нәрсәне белүен һәм күрүен, нәрсәне белмәвен һәм күрмәвен исәпкә алып, аңлаешлы сөйләм төзү, сораулар бирү
6. Партнёрның эш-гамәлләрен контрольгә алу;
7. Сөйләмнең диалог формасын үзләштерү.

**II.Укыту предметының эчтәлеге**

.

**Татар теленнән белем бирү максатлары:**

1. Укучыларда ана телен өйрәнүгә кызыксыну, омтылыш, эзләнүгә теләк уяту, үз милләтеңә, татар теленә мәхәббәт тәрбияләү кебек уңай сыйфатлар булдыру.
2. Балаларда татар теленнән мәгълүматлылык булдыру:
   - татар телендә аралашу күнекмәләре формалаштыру;
   - тел чараларын аралашу эчтәлегеннән чыгып сайлый белергә өйрәтү;
   - тел белеменең фонетика, лексика, грамматика бүлекләре буенча башлангыч белем бирү, өйрәнелә торган тел берәмлекләрен тикшерә һәм куллана белү күнекмәләрен булдыру;
   - сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре буенча күнекмәләр формалаштыру;
   - укучыларда татар теленә карата хөрмәт хисе һәм ихтирам тәрбияләү,телнең чисталыгын,дөреслеген саклап, халыкның рухи мирасын өйрәнүгә кызыксыну уяту.
3. Укучыларда аралашу өлкәсенә караган мәгълүмат булдыру.Сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча әйткәнне аңларга, аңлаганны тыңлаучыга җиткерергә, дөрес һәм матур итеп укырга, укыганның эчтәлеген сөйләргә ,аерым темаларга әңгәмәләр кора белергә,аралашканда , тел чараларыннан урынлы файдаланырга өйрәтү.
4. Сөйләм осталыгы һәм күнекмәләре формалаштыру.

5. Укучыларда татар этнокультура мәгълүматлылыгын үстерү.

**Төп бурычлар:**

- Укучыларда ана телен өйрәнүгә кызыксыну, омтылыш уяту.
- Балаларда татар теленең барлык тармаклары буенча компетенцияне булдыру.
- Укучыларда аралашу өлкәсенә караган мәгълүматлылыкны булдыру.
- Телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләре булдыру.

1 нче сыйныфта укучылар аваз һәм хәрефне аерырга өйрәнәләр, сүз басымы, исем, сыйфат, фигыль кебек сүз төркемнәре турында башлангыч мәгълүмат алалар. Сөйләм берәмлеге буларак җөмлә, аларны төрле интонация белән әйтү, сүзләрдән җөмләләр, җөмләләрдән хикәяләр төзи белү күнекмәләре дә бирү әһәмиятле. Укучыларның татар телен белү дәрәҗәсен исәпкә алып, укытучы дәресләрдә татар һәм рус теле үзенчәлекләренә тукталырга, тәрҗемә өлкәсенә караган биремнәр дә тәкъдим итәргә тиеш. Программада һәр сыйныфта бәйләнешле сөйләм үстерү өчен, аерым эш төрләре һәм темалар тәкъдим ителә. Сөйләм телен үстерү уку дәресләрендә дә дәвам иттерелә. Татар теле дәресләрендә укытучы халык авыз иҗаты үрнәкләреннән дә файдалана. Табышмаклар, әйтемнәр, санамышлар ятлау, аларны дәфтәрләргә матур язу да балаларны әдәби нормаларга туры килердәй итеп сөйләргә өйрәтүдә зур әһәмияткә ия булып тора.

**1 нче сыйныф укучыларының татар теленнән белем, осталык һәм күнекмәләренә төп таләпләр**

1. “Телдән әзерлек чоры” өчен тәкъдим ителгән темалар буенча бирелгән сүзләрне аңлап, кара-каршы һәм монологик сөйләмдә куллана белергә тиешләр.
2. Хәрефләрдән иҗекләр, иҗекләрдән сүзләр, сүзләрдән сүзтезмә һәм җөмләләр төзи белү, аларны дөрес итеп язу. Сүзләрне иҗекләргә бүлү, юлдан-юлга күчерү. Сүз басымын дөрес куеп уку.
3. Татар теленең үзенчәлекле сузык һәм тартык авазларын дөрес әйтү, бу авазларны белдергән хәрефләр булган сүзләрне язу. Татар теленең үзенчәлекле авазлары кергән сүзләрдәге аваз һәм хәрефләрне аерып әйтә белү.
4. Җөмләләрдән исем, фигыль, сыйфатларны табу. Җөмләдәге сүзләр бәйләнешен аңлату. Җөмлә ахырында тыныш билгеләрен интонациягә бәйле рәвештә кую.

**III. Төп уку эшчәнлеге төрләре күрсәтелгән тематик планлаштыру**

| № | Дәрес темасы | Уку эшчәнлеге төрләре | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|
| | | | |
| 1 | Танышу дәресе | Диалог, укытучы белән әңгәмә | 1.09 |
| 2 | Р.Бәшәр “Танышу” шигыре. БСҮ Әдәпле сүзләр. | Рәсем буенча әңгәмә китап белән эш | 5.09 |
| 3 | Сөйләмдә зат алмашлык ларын куллану | төркемдә эшләү нәтиҗә чыгару | 6.09 |
| 4 | Мәктәп, сыйныф укучылары һәм укытучылар | Диалог, парлап эш | 7.09 |
| 5 | Бу кем? Бу нәрсә? сораулары | Рәсемнәр белән эшли белү. Сөйләм | 8.09 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | телен үстерү. Сүзлек хәзинәсен арттыру. | |
| 6 | Г. Тукай. “Әлифба”.<br>Ш..Галиев “Таяк” шигыре. | Уку буенча конкурс | 12.09 |
| 7 | Нинди? Ничә? Кая? Кайда? сораулары | Диалог, парлап эшләү схема белән | 13 |
| 8 | Нишли? Нәрсә укый? Нәрсә белән? сораулары | Рәсем белән эш | 14 |
| 9 | Ничек? соравы | Диалог, парлап эшләү<br>Рәсем белән эш | 15.09 |
| 10 | Дәрдемәнд. “Балалар, әйдә мәктәпкә!” | Әңгәмә анализлау | 19.09 |
| 11 | Гаилә кешеләре | Диалог, укытучы белән әңгәмә | 20 |
| 12 | Гаиләдә өлкән кешеләр | Парлап эшләү,төркемдә эш | 21 |
| 13 | Гаиләнең адресы, тору урыны, җиһазлау | Диалог, парлап эш | 22.09 |
| 14 | . Вәлиева “Беренчеләр”.<br>Р.Миңнуллин “Кояш” шигыре. | Мини проект ясау | 26.09 |
| 15 | Гаилә кешеләре<br>нең һөнәрләре, белгечлеге | Рәсемнәр белән эшли белү. Сөйләм телен үстерү. Сүзлек хәзинәсен арттыру. | 27.09 |
| 16 | Кем? Нәрсә пешерә? | Диалог, парлап эшләү | 28 |
| 17 | Ашамлык<br>лар кибетендә | Рәсем белән эш | 29 |
| 18 | Э. Шәрифуллина. “Күзең күргәч”.<br>Х.Халиков “ Сакчы күркә” шигыре. | Рәсем ясау | 3.10 |
| 19 | Тән төзелеше | Диалог, парлап эшләү<br>Рәсем белән эш | 4.10 |
| 20 | Шәхси гигиена | Диалог, укытучы белән әңгәмә | 5.10 |
| 21 | Көндәлек режим | Парлап эшләү,төркемдә эш,режим төзү | 6.10 |
| 22 | БСҮ Туган телне өйрәнәбез.<br>Ш. Маннапов. “Ат ник көлә?”. | Китап белән эш | 10.10 |
| 23 | Өс-баш киемнәре | Диалог, парлап эш | 11.10 |
| 24 | Аяк киемнәре | Рәсемнәр белән эшли белү. Сөйләм телен үстерү. Сүзлек хәзинәсен арттыруга | 12 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | күнегүләр. | |
| 25 | Киемнәр кибетендә | Диалог, парлап эшләү | 13.10 |
| 26 | Р.Батулла “Әйлән-бәйлән уены” | Уеннар уйнау | 17.10 |
| 27 | Уеннар, уенчыклар | Рәсем белән эш | 18.10 |
| 28 | Яраткан уенчыгым | Диалог, парлап эшләү<br>Рәсем белән эш | 19.10 |
| 29 | Авылда. Яшелчәләр,җиләк-җимешләр. | Диалог, парлап эшләү, төркемнәрдә | 20.10 |
| 30 | Р. Батулла. “Аю Әппәс”. | Театр кую | 24.10 |
| 31 | Йорт кошлары, хайваннары | Презентация, интерактив уеннар | 25 |
| 32 | Кыргый хайваннар | Театр уены | 26.10 |
| 33 | Кошлар | Парлап эшләү, төркемдә эш | 27 |
| 34 | Ш.Галиев “Танышмак өчен табышмак”<br>БСҮ “Яраткан кошларыбыз һәм хайваннарыбыз” | Табышмаклар уйлау | 7.11 |
| 35 | Бездә кышлаучы һәм җылы якка очучы кошлар | Табышмак табу, презентация | 8.11 |
| 36 | Шәһәр тормышы<br>на караган атамалар | Картина буенча сөйләшү,әңгәмә | 9.11 |
| 37 | Шәһәр тормышы | Диалог, парлап эшләү<br>Рәсем белән эш | 10.11 |
| 38 | Г. Тукай. “Гали белән кәҗә” | Мултфилм карау әңгәмә | 14.11 |
| 39 | Шәһәр транспорты | Диалог, парлап эшләү, төркемнәрдә | 15 |
| 40 | Милли бәйрәмнәр | Презентация, интерактив уеннар | 16.11 |
| 41 | Сабантуй-татар халкының милли бәйрәме | Театр уены,китап белән эш | 17 |
| 42 | Г. Тукай “Бала белән күбәләк” “Карлыгач” шигыре. | Рәсем ясау | 21.11 |
| 43 | Милли бәйрәмнәр<br>дәге уеннар. | Парлап эшләү, төркемдә эш | 22 |
| 44 | [а] авазы һәм А, а хәрефләре | Табышмак табу, презентация | 23.11 |
| 45 | А, а хәрефләрен язу | Картина буенча сөйләшү,әңгәмә | 24 |
| 46 | Р. Вәлиева.“Күбәләк һәм кырмыска”, “Күбәләк белән керпе”. | Китап белән эш | 28.11 |
| 47 | [ә] авазы һәм Ә,ә хәрефләре | Рәсемнәр буенча парлап эш, төркемнәрдә эш | 29.11 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 48 | Ә, ә хәрефләрен язу | Дәфтәрләрдә эш , өстәмә әдәбият белән эш | 30.11 |
| 49 | [ы] авазы һәм Ы, ы хәрефләре | Парлап эшләү, төркемдә эш уен | 29 |
| 50 | Ы, ы хәрефләрен язу | Табышмак табу, презентация | 1.12 |
| 51 | Х. Халиков. “Укытучыларым” З.Мансур “Кырмыска” шигыре. | Әңгәмә, уен, видео карау | 5.12 |
| 52 | [ у] авазы һәм У, у хәрефләре | Картина буенча сөйләшү,әңгәмә | 6.12 |
| 53 | У, у хәрефләрен язу | Рәсемнәр буенча парлап эш, төркемнәрдә эш | 7 |
| 54 | [ ү] авазы һәм Ү, ү хәрефләре | Дәфтәрләрдә эш , өстәмә әдәбият белән эш | 8.12 |
| 55 | М. Әгъләмов. “Бүләк”. Г.Сабитов “Балага-бүләк” | Бүләк ясау төркемнәрдә | 12.12 |
| 56 | Ү,ү хәрефләрен язу | Презентация, интерактив уеннар | 13.12 |
| 57 | [ н] авазы һәм Н, н хәрефләре . Язу. | Театр уены | 14 |
| 58 | [с] авазы һәм С,с хәрефләре | Парлап эшләү, төркемдә эш | 15.12 |
| 59 | Такмаклар. | Җыр өйрәнү | 19.12 |
| 60 | С,с хәрефләрен язу | Табышмак табу, презентация | 20.12 |
| 61 | [к] авазы һәм К, к хәрефләре | Картина буенча сөйләшү,әңгәмә | 21 |
| 62 | К, к хәрефләрен язу | Диалог, парлап эшләү<br>Рәсем белән эш | 22 |
| 63 | Тел шомарткычлар. | Әйтеп карау күнегүләре | 9.01 |
| 64 | [йы] авазы һәм Е,е хәрефләре | Диалог, парлап эшләү, төркемнәрдә | 10.01 |
| 65 | Е, е хәрефләрен язу | Презентация, интерактив уеннар | 11.01 |
| 66 | [ г ] авазы һәм Г, г хәрефләре | Театр уены,китап белән эш | 12 |
| 67 | Шүрәле” әкияте белән танышу. | мултфилм | 16.01 |
| 68 | Г, г  хәрефләрен язу | Парлап эшләү, төркемдә эш | 17.01 |
| 69 | [ч] авазы һәм Ч, ч хәрефләре | Табышмак табу, презентация | 18 |
| 70 | Ч, ч хәрефләрен язу | Картина буенча сөйләшү,әңгәмә | 19 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 71 | Кола ат. (Татар халык әкияте). | | 23.01 |
| 72 | [ о] авазы һәм О, о хәрефләре | Рәсемнәр буенча парлап эш, төркемнәрдә эш | 24.01 |
| 73 | О, о хәрефләрен язу | Дәфтәрләрдә эш , өстәмә әдәбият белән эш | 25 |
| 74 | [ ө] авазы һәм Ө, ө хәрефләре | Парлап эшләү, төркемдә эш | 26.01 |
| 75 | Алдавыч әкият. “Мактанчык каз” | Рәсем әңгәмә | 30.01 |
| 76 | Ө, ө хәрефләрен язу | Табышмак табу, презентация | 31.01 |
| 77 | [ э] авазы һәм Э, э хәрефләре | Картина буенча сөйләшү,әңгәмә | 1.02 |
| 78. | Э, э хәрефләрен язу | Рәсемнәр буенча парлап эш, төркемнәрдә эш | 2.02 |
| 79 | Мәзәкләр. | Мәзәкләр сөйләү | 6.02 |
| 80 | [ң] авазы  һәм ң хәрефе | Дәфтәрләрдә эш , өстәмә әдәбият белән эш | 7.02 |
| 81 | ң  хәрефен язу | Презентация, интерактив уеннар | 8.02 |
| 82 | [йа] авазы  һәм Я я хәрефе | Театр уены | 9.02 |
| 83 | Табышмаклар. | Табышмаклар әйтү уены | 20.02 |
| 84 | Я ,я хәрефен язу | Парлап эшләү, төркемдә эш | 21 |
| 85 | [йу, йү] авазы һәм Ю ю хәрефе | Табышмак табу, презентация | 22 |
| 86 | Ю хәрефен язу | Картина буенча сөйләшү,әңгәмә | 23.02 |
| 87 | Санамышлар.<br>Р.Миңнуллин “Саный беләм” | Санамышлар өйрәнү | 27.02 |
| 88 | [в,w]авазлары һәм В в хәрефе | Диалог, парлап эшләү<br>Рәсем белән эш | 28.02 |
| 89 | В, в хәрефен язу | Диалог, парлап эшләү, төркемнәрдә | 1.03 |
| 90 | Ъ билгесе | Презентация, интерактив уеннар | 2 |
| 91 | Г. Хәсәнов. “Ел язга аяк атлады” | Яз турында таблиа ясау | 6.03 |
| 92 | Сүзләрдә Ъ билгесен язу | Театр уены,китап белән эш | 7 |
| 93 | Ь билгесе | Парлап эшләү, төркемдә эш | 8 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 94 | Сүзләрдә Ь билгесен язу | Табышмак табу, презентация | 9.03 |
| 95 | Г. Галиев “Кояш”.<br>С.Сөләйманова “Кем уяткан Ләйләне” шигыре. | Әниләр турында | 13.03 |
| 96 | [җ ] авазы һәм Җ җ хәрефе | Картина буенча сөйләшү,әңгәмә | 14 |
| 97 | Җ , җ хәрефен язу | Рәсемнәр буенча парлап эш, төркемнәрдә эш | 15 |
| 98 | [ һ] һәм Һ, һ хәрефе | Дәфтәрләрдә эш , өстәмә әдәбият белән эш | 16.03 |
| 99 | Һ хәрефен язу | Парлап эшләү, төркемдә эш | 29.03 |
| 100<br>101<br>102 | Й хәрефе, [й] авазы, әлеге авазларны язу.<br><br>Ш. Галиев. “Яз”, Н. Каштанов “Болыт”.<br>Й хәрефен язу | Табышмак табу, презентация<br>Дәфтәрләрдә эш | 30.03<br>3.03<br>4.03 |
| 103 | Хәрефләр патшалы<br>гында | Картина буенча сөйләшү,әңгәмә | 5.04 |
| 104 | Әлифбаны “озату” | Рәсемнәр буенча парлап эш, төркемнәрдә эш | 6.04 |
| 105 | Ш. Галиев. “Яз”, Н. Каштанов “Болыт”. | Рәсем ясау | 10.04 |
| 106 | Сөйләм. Аралашу әдәбе. | Дәфтәрләрдә эш , өстәмә әдәбият белән эш | 11.04 |
| 107 | Сүз. Сүз һәм иҗек. | Презентация, интерактив уеннар | 12 |
| 108 | Авазлар һәм хәрефләр. | Театр уены | 13 |
| 109 | С.Муллагалиев “Яз иде”<br>Ә.Бикчәнтәева “Җил сөйләшә беләме?” | Сөйләм күнегүләре | 17.04 |
| 110 | Алфавит. Алфавитны күчереп язу. | Парлап эшләү, төркемдә эш | 18 |
| 111 | Баш хәрефтән языла торган сүзләр.<br>Күчереп язу “Татарстан” | Табышмак табу, презентация | 19 |
| 112 | Хаталар өстендә эш.Сузык авазлар. | Картина буенча сөйләшү,әңгәмә | 20.04 |
| 113 | БСҮ. Бүген Тукай туган көн. Г.Тукай “Яз” | Албом ясау әңгәмә | 24.04 |
| 114 | Тартык авазлар. | Диалог, парлап эшләү | 25 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Рәсем белән эш | |
| 115 | Сүзләрне юлдан-юлга күчерү. | Диалог, парлап эшләү, төркемнәрдә | 26 |
| 116 | Сузык аваз хәрефләрен дөрес уку һәм язу. | Презентация, интерактив уеннар | 27.04 |
| 117 | Дәрдемәнд.” Гали”<br>Җ.Тәрҗеманов “Биш чия”. | Рәсем ясау | 1.05 |
| 118 | Я,ю,е хәрефләре | Театр уены,китап белән эш | 2.05 |
| 119 | Тартык аваз хәрефләрен дөрес уку һәм язу. | Парлап эшләү, төркемдә эш | 3.05 |
| 120 | Диктант “Май ае” | Табышмак табу, презентация | 4 |
| 121 | И. Туктар. “Өлгер”<br>Л. Лерон. “Супермалай”. | Схема ясау | 8.05 |
| 122 | Хаталар өстендә эш. Й, в,к,г хәрефләренең дөрес язылышы. | Картина буенча сөйләшү,әңгәмә | 9 |
| 123 | Сүз басымы. | Рәсемнәр буенча парлап эш, төркемнәрдә эш | 10 |
| 124 | Исем сүз төркеме. | Дәфтәрләрдә эш , өстәмә әдәбият белән эш | 11 |
| 125 | Ф. Яруллин “Хикмәтле сүз”.<br>Р.Вәлиева “.Дуслык” | Кагыйдә чыгару | 15.05 |
| 126 | Фигыль сүз төркеме. | Парлап эшләү, төркемдә эш | 16.05 |
| 127 | Сыйфат сүз төркеме. | Табышмак табу, презентация | 17 |
| 128 | Җөмлә. Җөмләдә сүзләр бәйләнеше. | Картина буенча сөйләшү,әңгәмә | 18 |
| 129 | Г. Зәйнашева. “Бер атнада ничә көн?”<br>Ш.Галиев “Светофорның өч күзе” | Рәсем ясау әңгәмә | 22.05 |
| 130 | Җөмлә ахырында тыныш билгеләре. | Рәсемнәр буенча парлап эш, төркемнәрдә эш | 23.05 |
| 131,132 | Өйрәнгәннәрне йомгаклау. | Төркемнәрдә кызыклы уеннар,викторина | 24.05,25.05 |

Пронумеровано, прошнуровано
и скреплено печатью одиннадцать листов
Учитель ____ И.Х.Замалиева